**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**«18» ноябрь 2019 ел** **№ 137**

**Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге 71 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 71 номерлы «Җир салымы турында " карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 статьяның 2 пунктына түбәндәге сүзләр өстәргә " (индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган)»;

5 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алынган җир участогы турында хәбәрнамә салым органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы икенче абзацы 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы урамы, 9;
- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов урамы, 9, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Башлыгы,**
**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Советы рәисе** **А.Г.Җиһаншин**